РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского муниципального
района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«25» 03 2022 № 78

Аксубаево

2022 елга Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьялары, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»13.07.2007 ел, № 31-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарны исәпкә алганда һәм торак белән тәэмин иткәндә, торак мәйданы нормалары турында» 30.12.2009 ел, № 329 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 29.04.2021 ел, № 134 карары, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 31.01.2022 ел, № 24 «ТР Бәяләүчеләр союзы» КП лыгы бәяләве нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1 Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

- ялгыз яшәүче гражданга 786 027 сум;
- ике кешелек гаиләгә 1 000 398 сум;
- өч кешелек гаиләгә 1 286 226 сум;
- дүрт кешелек гаиләгә1 714 968 сум;
- биш кешелек гаиләгә 2 143 710 сум;
- алты кешелек гаиләгә 2 572 452 сум;
- җиде кешелек гаиләгә 3 001 194 сум;
- сигез кешелек гаиләгә 3 429 936 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма кеременең чик күрсәткече күләме:

- ялгыз яшәүче гражданга – 23 858,07 сум;
- ике кешелек гаиләгә – 15 182,41 сум;
- өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә – 13 013,49 сум.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә әлеге карарда күрсәтелгән чик күрсәткечләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» 03 2022 № 78
карарына кушымта

2022 елга
Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урыны алу өчен түләүсез субсидияләр исәпләү өчен башкарма хакимиятнең тиешле федераль органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның уртача базар хакының артмый торган уртача исәп-хисап хакы.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 31.01.2022 ел, № 24 «ТР Бәяләүчеләр союзы» КП хаты нигезендә, Аксубай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метрының уртача базар хакы 23 819 сум тәшкил итә.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 23 819 х 33 = 786 027 сум;
б) ике кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 42 = 1 000 398 сум;
в) өч кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 18 х 3 = 1 286 226 сум;
г) дүрт кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 18 х 4 = 1 714 968 сум;
д) биш кешелек гаиләгә
СЖ = 23 819 х 18 х 5 = 2 143 710 сум;
е) алты кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 18 х 6 = 2 572 452 сум;
ж) жиде кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 18 х 7 = 3 001 194 сум;
з) сигез кешелек гаиләгә:
СЖ = 23 819 х 18 х 8 = 3 429 936 сум.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә,

- СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 х РС), биредә

ПД - гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләнгән хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма); елга 12 % (коммерциячел кредит оешмаларының ачык чыганакларыннан мәгълүмат буенча), ягъни аена 12/12/100 = 0,01 (аена)).

КП – кредитның барлык чорына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир хакының нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең һәм гаиләнең айлык җыелма кеременең нисбәте..

## Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү

Табл. №1

| НП - торак урын нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар хакы (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше саны) | РЦ - торак урынның 1 кв. м базар хакы (сум.) | ПС - Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы, % | КП - Кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасының һәм фатир хакының нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | Керемнең чик күләме (сум) (бер кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 23 819 | 12/12/100= 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 786 027 | 1 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | 22 011,84 |
| 42 | 1 000 398 | 2 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,6 | 14 007,53 |
| 54 | 1 286 226 | 3 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,9 | 12 006,46 |
| 72 | 1 714 968 | 4 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,2 | 12.006,46 |
| 90 | 2 143 710 | 5 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,5 | 12 006,46 |
| 108 | 2 572 452 | 6 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,8 | 12.006,46 |
| 126 | 3 001 194 | 7 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,1 | 12 006,46 |
| 144 | 3 429 936 | 8 | 23 819 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,4 | 12.006,46 |

Гражданның һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең чик күрсәткечен исәпләү-

1. Ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 786027 х 0,01 / (1-1/1,01$^{180}$) / (0,3х1) = 5502,189/(1-0,16678)/0,3 = 5502,189/0,8332166/0,3 = 22 011,84

2. Ике кешелек гаиләгә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1000398 х 0,01 / (1-1/1,01$^{180}$) / (0,3х2) = 7002,786/(1-0,16678)/0,6 = 7002,786/0,8332166/0,6 = 14 007,53

3. Өч һәм аннан да күбрәк кешелек гаиләсенә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1286226 х 0,01 / (1-1/1,01$^{180}$) / (0,3х3) = 9003,582/(1-0,16678)/0,9 = 9003,582/0,8332166/0,9 = 12 006,46